Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы
карары

№ 3 20.10.2022

Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге Аграмак торак пунктында 2023 елда үзара салым кертү һәм куллану буенча гражданнар җыены билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАРЫ:

1. 2023 елда Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлегенең Аграмак торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 1нче этабын Татарстан Республикасы, Спас районы, Аграмак авыл мәдәният йорты бинасында 2022 елның 8 нче ноябренә 14.00 сәгатькә билгеләргә.
2. 2023 елда Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлегенең Аграмак торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 2нче этабын Татарстан Республикасы, Спас районы, Аграмак авыл мәдәният йорты бинасында 2022 елның 9 нчы ноябренә 14.00 сәгатькә билгеләргә.
3. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләләрне расларга:

“Спас муниципаль районының Аграмак авыл җирлегегенә кергән Аграмак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, һәм 1нче группа инвалидлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 250 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән сез килешәсезме?:

- Аграмак торак пунктында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам утларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

-Аграмак торак пунктында юлларны кардан чистарту, грейдерлау (ягулык – майлау материаллары, МТЗ-82 тракторына запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Аграмак торак пунктында җәйге чорда территорияне чабу (ягулык – майлау материаллары, МТЗ-82 тракторына запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Аграмак торак пунктында чүплекләрне эттерү (чүп мәйданчыкларын карап тоту) (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Аграмак торак пунктында бәйрәмнәрне оештыру һәм үткәрү: Авыл көне, Халыкара өлкәннәр көне, Яңа ел (канцелярия товарлары, бүләкләр, сувенирлар сатып алу.);

“ӘЙЕ” “ЮК”

4. Әлеге карарны Аграмак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Аграмак авыл җирлегенең рәсми сайтында http:/ www. spasskiy.tatarstan.ru, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Аграмак авыл җирлеге башлыгы Р.Т. Галәветдинова

СОВЕТ АГРАМАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ